


# Без кабызган утлар

**яңа клуб сезоны ачылу, мәдәният йортының 50 еллык юбилее уңаеннан әзерләнгән кичә-бәйрәм.**

*Бәзәкә авылы, 11.11.2017ел.*

Көн артыннан көн, ай артыннан ай узып, туган авылыбыз өчен истәлекле вакыйгаларга бай булган 2017 ел да узып бара. Бу истәлекле вакыйгалар Альта апа Махмутованың “Бәзәкәм, туган бишегем” дигән китабын бастырып чыгарганнан соң башланып китте.Иң элек шушы мәдәният йортында китапны тәкъдир итү чарасы булды, август аенда авылның 500 еллык юбилее сабантуй белән бергә зурлап уздырылды. Ә мәдәният учакларында ел дәвамында барлык чаралар “Бәзәкәгә-500 ел!” дигән девиз астында үтте. Ә инде 11 ноябрьдә мәдәният йорты тагын бер матур бәйрәмгә узенең кунакларын җыйды. 2017 елнын 6 ноябрендә Мәдәният йорты ачылуга 50 ел тулды! Быел яңа сезон ачылу концертын без шушы юбилей белән бәйләргә булдык. Мәдәният йортында инде көздән бирле шушы чарага әзерлек барды. Авылның үзешчән сәнгать артистлары көзге кичләрне яңа бер дәрт, омтылыш белән мәдәният йортында концертка әзерләнделәр. (Тырышлыгыбыз бушка китмәгәндер дип ышанасы килә!)

Безнең мәдәният йорты чагыштырмача тиз арада төзелә, чөнки 1967 елда аны Бөек Октябрьнең 50 еллыгына файдалануга тапшыру планлаштырылган була. Төзелештә үзебезнең Бәзәкә хатын-кызлары Хабибуллина Сәҗидә, Шаймарданова Газдәбикә, Бәхтегараева Нәгыймә, Минигулова Минҗиһан, Габдрахманова Сабира апалар хезмәт куялар. Клубны ачар көн якынлашкан саен эш темпы үсә бара. Төзүчеләргә ярдәмгә авыл апалары да килә.1967 елның 5 ноябрь кичендә фермадан су ташып бөтен клуб идәнен юып

чыгаралар, тәрәзә төпләрен гөлләр куеп бизиләр. Ә челтәрләрне төне буе алтын куллы Нәгыймә апа тегә һәм иртән тәрәзәләргә китереп элә. Гадәттәгечә, 6 ноябрь көнне авылда демонстрация була. Аннары бар халык яңа мәдәният йортына агыла. Бу кичтә яңа клуб сәхнәсендә бәзәкәлеләр генә түгел, күрше Сәйтәк, Тәкәш авылы үзешчәннәре дә аерым концерт куялар. Әлбәттә, районда иң зур авылларның берсе саналган Бәзәкәдә шундый зур мәдәният йорты ачылгач авыл халкының, бигрәк тә яшьләрнең сөенече чиксез була. Ә мәдәният йорты ачылу тантасында тырыш хезмәтләре өчен Газдәбикә апа белән Сажидә апа тегү машинасы, Нәгыймә апа самовар белән бүләкләнә. Күз алдына китерегез, шул чор өчен нинди шатлыклы, гомергә истә калырлык мизгелләр!

Ә яңа клуб утларын биредә эшләүче Ахметзянова Вәгыйдә белән Хурматуллина Мәэмүсә апалар кабыза. Мәдәният йорты директоры булган Вәгыйдә апа булдыклы, эшчән, югары профессиональлеге белән авылдашларының күңелен яулаган мәдәният хезмәткәре була, ә концертларда халык аның моңнарына уралып ял итә. Юбилей кичәсендә Вәгыйдә апаның Алабуга шәһәрендә яшәүче кызы Гыйлфанова Лилия апаның катнашуы да бәзәкәлеләрнең күңеленә хуш килде.

Әйдәгез, хәзер 60-70-нче елларга күчик. Яшьлеге шул елларга туры килгән авылдашлар, ишетәсезме, хәтерлисезме? Бу елларда сезне мәдәният йорты һәр кич нинди музыка белән каршы ала иде?. Бу елларда Бәзәкә мәдәният йорты утларын яшь белгечләр Хәким һәм Нәкыя Фаразутдиновлар кабыза. Оста гармунчы Хәким абый белән оста биюче Нәкыя апа эшләгән чорны бәзәкәлелер әле хәзер дә сагынып искә алалар. Бу гаилә бөтен күңелләрен, вакытларын яраткан эшләренә багышлый. Мәдәният йорты тәүлек буе гөрләп тора - төрле түгәрәкләр эшли, кичләрен яшьләр бильярд, теннис уйныйлар, күңел ачалар. Мәдәният ул - һөнәр генә түгел, ә яшәү кыйбласы. Булган, талантлы, максатчан Нәкыя апа бүген районның танылган “Шаян” халык бию ансамбле җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Үзенең ансамбле белән ул ярты җир шарын гизеп чыкты.

Музыка дөньясына күз салсак, 60-70-нче елларны музыка дөньясы өчен революцион еллар дип атарга мөмкин. Бөтен көнбатыш котырып “Битлз”, “АББА” ансамбльләрен тыңлый. Безнең Советлар Союзы да калышмый - бер-бер артлы сәхнәләрне «Ариэль», «Поющие гитары», «Голубые гитары», «Пламя», «Синяя птица» ансамльләре яулый. Музыкага һәвәс Бәзәкә егетләре дә берләшеп ансамбль төзеп җибәрәләр – Хөснетдинов Хәмзә белән Көләчев Рифат гитарада уйный, Гайнуллин Рифкать барабанчы була. Шулай итеп бу елларда авыл яшьләре тере музыкага бииләр.Алга китеп шуны әйтәсем килә, 90 елларда бу егетләргә алмашка инде яшьрәк буын егетләре килә: Рашат Хузиахметов, Камил Зәйнуллин, Илшат Сабитов, Рамил Нәбиуллин, Айдар Шиабиев- бу егетләр гитарада, Рөстәм Хабибуллин-барабанда уйныйлар. Әле алай гына да тугел, Рамил белән Рөстәм сеңелләрен дә ансамбльгә тарталар, Лилия Набиуллина (хәзер Ахмастинова) синтезаторда, ә мине- Гузәлия

Хабибуллинаны (хәзер Гомәрова) бас гитарада уйнарга өйрәтәләр. Шундый мавыктыргыч мизгелләр һаман истә, гитарада уйнарга өйрәтуләре өчен рәхмәт аларга!

80-нче елларда Бәзәкә мәдәният йорты утларын яшь белгечләр –Әлфия Тимергәлиева, шушы авылда туып-үскән талантлы кызлар - режиссерлык бүлеген тәмамлаган Гимашева Рәмзия (Сабитова), хор бүлеген тәмамлаган Гайнетдинова Зөһрә (Ситдикова), хореография бүлеген тәмамлаган Мухаметзянова Гөлсәрия апалар кабыза. Кичләрен Бәхтегәрәев Вәгыйз абый кино күрсәтә, Хузиахметова Нәсимә апа билет сата. Партия эше, идеология көчле ул елларда мәдәният хезмәткәренең эше һәр иртәне колхозның партком секретаре бүлмәсеннән башлана. Көне буе фермаларда, кыр станнарында йөреп арыган кызлар кичен авыл халкына рухый азык өстиләр. Шул елларда 20-25 кешедән торган хор, Набиуллин Рамиль, Шиябиев Фәрит, Зөһрә апа үзе, Аликин Нурулла, бертуган Гизатуллиннар Ильяс һәм Ильгиз, Зайнуллин Камиль, Шакиров Фәрит, Хикматуллин Кәүсәр, Шәймарданов Сәетнур абый, Ахметзянов Нургали катнашында баянистлар ансамбле, берничә кешедән торган “Ложкари” ансамбле оеша. Хор районның смотр концертында уңышлы чыгыш ясый, “Ложкари” ансамбле җиңү яулап Казанга узалар. Ә сәхнәдә талантлы җырчыларыбыз Сабитов Рафаиз абый белән Роза апа, Гизатуллина Фатыйма апа һәм биючеләр Мәхмүтова Әнисә апа, Тазиев Сәләхи абый, Сабитов Мехәмәтнур абый, Хисаметдинов Хаҗиәхмәт абый, Бәхтегараева Мөнирә апалар популярлык яулыйлар.
Минем карашка мәдәният - ул иҗади мөмкинлекләр ачу һәм аралашу мәйданы. Зыялы, карашы киң булганнар белән аралашканда, фикерләшкәндә генә җан азыгы, күңел рәхәтлеге, рух сихәтлеге аласың, югары әхлакый кеше булып каласың. Бу апалар белән сөйләшкәндә дә клуб эше нәкъ шуларга корылганын аңлыйсың.

**90-**нчы елларда Бәзәкә мәдәният йорты утларын Гизатуллин Ильгиз, Хабибрахманова Ясминур, Гильфанов Мансур абый , Насифуллин Рамилләр кабызалар. Алабуга мәдәният-агарту училищесын тәмамлап килгән җор телле, матур тавышлы Ясминур апа белән баянчы Ильгиз абый ул елларда сәхнәдән төшмиләр. Ә Мансур абый гомумән озак еллар мәдәният йортында аккомпаниатор булып эшли.

Барыгыз да минем белән килешерсез- безнең татар халкы театр ярата. “Театр яктылыкка, нурга илтә, Кире юлга җибәрми, уңга илтә”. Бөек Тукай сүзләре бу. Бу сүзләр безнең авыл халкына да тәңгәл килә. Һәм 80-90-нчы елларны без авылыбызның мәдәният тормышын театр белән бәйләп карасак дөресрәк булыр. Безнең Бәзәкә урта мәктәбендә тынгысыз күңелле, искиткеч бай телле, һәр эшкә бөтен җаны-тәне, бөтен барлыгы белән алына торган күркәм зат эшләде – ул Рәмзия апа Мөхетдинова. Укытучы булуы белән беррәттән эшчәнлегендә иҗади сәләтне үстерү, гореф-гадәт, йола-бәйрәмнәрне җанландыру һәм саклау, кәсеп-һөнәрләрне торгызу, яшь буынны

милли рухта тәрбияләүне өстенлекле итте Рәмзия апа. Һәм театр коллективы белән эшләү аның тагын бер өстенлеге иде. Ул елларда укытучылар коллективы һәм авыл яшьләре тарафыннан сәхнәгә күп спектакльләр куелды. 80-нче елларда бу спектакльләрне Казаннан махсус чакырып китерелгән режиссер Лариса Гаязовна Сайфуллина әзерли иде. Соңрак укытучылар коллективы куясы спектакльләрне Рәмзия Гараевна үзе әзерләде һәм бу эшне уңышлы башкарып чыкты. Күңелле ял сәгатьләре бүләк иткән, талантларны саклый, үстерә, осталыкларын камилләштерә барып, рухи азык өләшкән Рәмзия апага бүген рәхмәт әйтәсе, ныклы сәламәтлек, рухыбызны агарту юлында имин һәм нәтиҗәле хезмәт телисе килә!

Без бүген Мәдәният йортының 50 еллык юбилеен бәйрәм итәбез. Ә бит безнең авылда мәдәният йорты аңарчы да булган. Әйдәгез, шул елларга күз салыйк әле, кемнәр кабызды икән ул чакларда клуб утларын?
Бәзәкә авылында беренче клуб турындагы мәгълүматлар 1943 елдан башлана. Иске клубта ул елларда кемнәр эшләгәнен Шәргыя апа Ибатуллина сөйли: "Төрле елларда Ахметзянов Галиәхмәт, Ибраев Халиулла, Ибатуллина Шаргыя, Төхвәтуллин Хаҗи, Исмәгыйлов Минегали, Бикмухаметов Шәриф эшләде". 1953 елдан клубта яңадан Шәргыя апа эшли башлый. 1953-56 елларда бер айга өч спектакль куя идек, 7 шәр ат җигеп күрше авылларга да бара идек. Ул вакытта "Чаткылар", "Зәңгәр шәл", "Галиябану", "Нәфисә" спектакльләре куелды,- дип искә ала Шәргыя апа. 1959 елда клуб утын Ибәтуллина Әлфия апа, аннан соң оста баянчы Насифуллин Хажи абый кабыза. Ә Гыйлфанов Зәки абый кино күрсәтә.(Ул елларда спектакльләрдә минем әткәй белән әнкәй - Хабибуллин Зиннур, Хайдарова Фәрдәвия бик актив катнашалар. "Бүре малае " спектаклендә әнкәй хисапчы кыз ролен башкара, әткәй хисапчы кызга гашыйк булган гади колхозчы егетне уйный. Пьессада шундый сузләр була: "8 мартта безнең туй!", ә авылдашыбыз Шәрәфетдинова Наталья апа бу сузләрне спектакльдән түгел, чынлыкта дип уйлый, 8 мартта Зиннур белән Фәрдәвия өйләнешәләр икән дип ышана. Менә бит, Наташа апаның юраганы юш килә, оста гармунчы егет Зиннур белән зоотехник булып эшләүче яшь белгеч Фәрдәвия ел ярым вакыттан соң чыннан да өйләнешәләр, тик вакыты гына 30 декабрь көнне була...).

Авылда ул елларда халыкка үзләренең искиткеч матур тавышлары белән күңелләреннән чыккан моңны Галиев Сәетгали, Ибәтуллин Әхәт, Ахметшин Галиәхмәт, Миннахметов Нурый бүләк итәләр. Калимуллин Минәхмәт полька биюен зур осталык белән башкара, Гайнуллин Мулланур абый оста биюче булу өстенә сальто башкарып авылдашларын шаккаттыра.
Менә шулай итеп халкыбыз үзенә генә хас рухи культура җәүһәрләрен саклап кала алган. Киләчәктә дә мәдәниятле милләт булып саклану өчен безгә яшь буынны халкыбызның культура мирасы белән даими таныштырып тору, аны тарихыбызга хөрмәт белән карарга өйрәтү зарур. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, дип тикмәгә генә әйтмиләр бит!

Юбилей кичәсендә тагын бер кеше турында әйтеп китмичә ярамаган булыр иде. Сүз 30 елдан артык авылыбызда колхоз рәисе булып эшләгән Ибраһим Миндарович Галимов турында. Милли мәдәниятебезгә, матур традицияләребезгә ихлас күңелдән гашыйк, җан атып йөрүче кеше иде ул. Бәзәкәгә аяк басканнан бирле ул мәдәният тормышы белән кызыксынып яшәде, үзе дә чараларда актив катнашты, яшьләрне милли традицияләрдә тәрбияләү өчен көчен түкте. Күп чараларның иганәчесе булды. Сәхнәгә аяк баскан һәркемне хуплады, үсендерде, җылы сүзен әйтте, акыллы киңәш-тәкъдимнәрен җиткерде. Көчле рухлы, оста телле, үткен акыллы җитәкче бүген безнең арада юк инде. Бүген әйтелгән сүзләр аның рухына дога булып барып ирешсен иде!

90-нче еллар зур үзгәрешләр, күп яңалыклар кичергән чор. Безнең мәдәният йорты да бу елларда күп җитәкчеләрне алыштырды, яңа директор, художество җитәкчеләрен кабул итте. Бигрәк тә 93-99-нчы еллар аралыгында кадрлар алышынуы кискен үсеш алды. Әммә дә ләкин мәдәният учагы сүнмәде, дөрләп, ялкынланып янды. Ул вакытта истә калган зур чараларның берсе “Каз өмәсе”, авылдашыбыз Марсель абый Гыймазетдиновка багышланган кичә булды. Ул вакытта, бүгенгедән аермалы буларак, клуб белән мәктәп берлектә эшли иде. Директор Гимазов Дамир абый, укыту һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары Мехәмәтнур абый Сабитов, Шәмсия апа Гимазова, педагог – оештыручы Рәмзия апа Мөхетдиновалар җитәкчелеге астында район күләмендә генә тугел, республика күләмендә матур чаралар оештырыла иде.

Менә шулай әкренләп яңа гасырга да аяк бастык. Минем бу урында 2000-нче еллардагы нәни сәхнә йолдызларына тукталып, аларнын исемнәрен әйтеп үтәсем килә. Ул елларда мәдәният учагын дөрләткән Юлия Иванова, Диана Шиабиева, Эльвина Ефимова вокал өлкәсендә зур уңышларга ирештеләр. Биючеләребез Миләүшә Гизатуллина, Гүзәл Ахмастинова, Гөлназ Хикматуллина, Азат Галимов, Раил Насифуллин, Риназ Хикматуллиннар үзләренең осталыклары белән тамашачыларның мәхәббәтен яуладылар. Югары уку йортларын тәмамлап, зур тормыш юлына аяк бассалар да Юлия, Гүзәл, Раил һәм Рөстәм Калимуллин бүгенге көндә дә яраткан тамашачысына хезмәт күрсәтәләр.

Яңа гасырга менә шундый моңлы җырлар, дәртле биюләр, яңа максатлар белән кереп киттек, биек үрләр, дәрәҗәле исемнәр яуларга насыйп булды. Бу вакытта Гимазова Гөлнар, Насифуллина Розалия, мин ,(бер бер артлы директорлар), Дамир абый- аккомпаниатор булып эшләдек. Венера апа белән Мансур абый Хузиахметовлар, Сәетҗан абый Ибатуллин мәдәният йортының чисталыгын, төзеклеген һәрвакыт югары дәрәҗәдә тоттылар.

Бу вакытта мәдәният өлкәсендәге үзгәрешләр күбрәк театр белән бәйле дип әйтер идем мин. Укытучылардан һәм авыл яшьләреннән торган театр коллективлары, ел саен спектакль куюны максат итеп алып халыкка зур дәрәҗәдә хезмәт курсәттеләр.

Вокал өлкәсендә район күләмендә Илшат Шакиров, Алсу Мусина, Рашат Хузиахметов югары дәрәҗәдә дипломнар белән бүләкләнеп авылыбызның абруен күтәрделәр. Бәйрәм концертларыбыз ял көненә туры килгән вакытта кунакка кайткан авылдашларыбыз Ризәлә Исмагилова, Мөнирә апа Бәхтегараева, Гөлшат апа Хузиахметова үзләренен чыгышлары белән безне дә, тамашачыны да сөендерә иделәр. Бу бүгенге көндә дә шулай дәвам итә, Аллага шөкер!

Шул елларда безгә тагын бер бәхет елмайды- без яңа аппаратуралы булдык. Авыл җирлеге башлыгы - Мансура апа Салимуллинага без шуның өчен бик рәхмәтле!

2010 еллар якынлашыр алдыннан безнең “Бизәк”бию төркемендә яңа биюче кызлар төркеме барлыкка килде. Шуның кадәр чая, тиктормас кызларыбызның да исемнәрен сезгә ишеттерәсебез килә: Шиабиева Эльвира, Нигаметзянова Айсылу, Гилязова Айсылу, Гомәрова Эльвина, Сиразетдинова Раиля, Ефимова Эльза, Набиуллина Зилә, Набиуллина Алсу, Миронова Аделина. Бу кызларыбыз төрле райондагы чараларда, конкурсларда, бәйрәм концертларыбызда актив катнашучыларыбыз булды. Бүгенге көндә аларның күбесе студентлар, дипломлы белгечләр. Зилә, Алсу, Аделина Менделеев шәһәрендә урта мәктәптә белем алалар. Шуңа да карамастан, алар бүген дә безнең сәхнә йолдызларыбыз.

2015 елның октябрь аенда безнең авылыбыз тарихы өчен тагын бер сөенечле вакыйга булды- “Минем Бәзәкәм” сайты эшли башлады. Аның презентациясе авыл мәдәният йортында узды. Бу сайт безнең төрле илләргә, төрле төбәкләргә таралып урнашкан авылдашларыбызны аралаштыра һәм берләштерә. Бу зур хезмәтләре өчен киң куңелле, кече иленең чын патриотлары булган авылдашларыбыз Рәшит абый Кәлимуллинга һәм Лилия апа Мөнировага барлык авылдашларыбыз исеменнән рәхмәтебез чикчез!

2016 елда мәдәният йортыбызда капиталь ремонт ясалу авылның мәдәният тормышына яңа бер сулыш өрде. Район җитәкчеләре Бәзәкәдә стандарт проект буенча яңа клуб-МФЦ (многофункциональный центр) төзергә кирәк дигән фикергә килгәннәр иде. Ул вакытта авыл җирлеге башлыгы Розалия Насифуллинаның, авылыбыз тормышы өчен янып яшәүче авылдашларыбызның үҗәтлеге аркасында, район җитәкчеләре иске клубка ремонт ясарга кирәк дигән нәтиҗәгә килделәр. Күз алдыгызга китерегез әле:

100 урынлы зал нәрсә бирер иде безнең мәдәният йортына? Бүген залда 300 урын, ә күпме халык басып тора- бу бик уңайсыз булыр иде безнен авыл өчен. Аллага шөкер, үзебезнен әби-бабайларның, эти-әниләрнең, талантлы авылдашларыбызның, мәшһүр Әлфия Авзалова, Илһам Шакировларның эзләрен саклаган сәхнәбезне саклап калдык бүгенгесе көндә! Матур итеп ремонт ясагач ул безнең өр-яңа мәдәният йортына әверелде. Бүгенге көндә биредә бию, аэробика, вокал , театр түгәрәкләре эшли.

50 еллык юбилей бер генә була. Шуңа күрә мин актив авылдашларның һәрберсенең исемен атыйсым килә. Алар бүген һәм узган елларда, үзләренең вакытларын кызганмыйча, мәдәният йортына килеп халыкка хезмәт итүчеләр

”Бизәк” бию түгәрәге:

- Кечкенәләр төркеме: Гимазов Рафаэль, Ростов Данил белән Адель, Закиров Алмаз, Хузиахметов Айзат, Рдаева Рания, Нуретдинова Азалия.
- Урта төркем кызлары: Мусина Резидә, Мустафина Ангелина, Гильмутдинова Зилә белән Алия, Нуретдинова Алинә, Бахтегараева Динара, Хузяхранова Регина.

Вокал:

- Назмутдинова Гөлшат, Хузиахметов Рашат, Хузиахметова Эльмира, Гильмутдинова Венера, Шакиров Ильшат, Гатауллина Гузәл, Мусина Алсу, Закирова Әклимә, Башарова Фәния, Шайдуллина Кәүсәрия.

Театр:

- Гараев Фәрит, Расим белән Рәвия Мусиннар, Рәфис белән Тәнзилә Сибгатуллиннар, Ильсур белән Фәйрүзә Хузиахметовлар, Насифуллина Розалия, Фәймә, Ринат, Айрат, Рәшит Галимовлар, Садриева Фәридә, Хикматуллин Кәүсәр, Салаватуллин Рамиль, Хабибуллина Алсу, Рәфис һәм Рәмзия Мөхетдиновлар, Мехаматнур һәм Рәмзия Сабитовлар, Калимуллина Рәвилә, Миннебаев Ильдар, Башарова Эльмира, Ефимова Лилия, Салихов Марат, Шакиров Ленар һ.б.

Аэробика түгәрәгенә йөрүче хатын кызларыбыз да бик актив безнең. Алар сәламәтлекләрен ныгытырга клубка киләләр, ә без әкренләп аларны да сәхнәгә тартабыз. Мероприятиеләр вакытында алар да ярдәм итәргә ашкынып торалар, кем материал, кем күлмәк алып килә, кем костюм тегәргә булыша:

- Плотникова Мәсхүдә, Мухаметзакирова Рәмилә, Сиразетдинова Гөлфия, Хуснутдинова Рәйсә, Закирова Әклимә, Набиуллина Миләүшә, Кашбиева Инзилә, Хисамудинова Рәзилә, Хузиахметова Фәйрузә, Галимова Фәймә, Татьяна Ивановна, Шакирова Сания, Гатауллина Раушания, Фархиева Римма, Исмагилова Фәйрүзә, Шайдуллина Кәүсәрия, Хурматуллина Рәүфә апаларга, Нуретдинова Гөлнур, Гимазова Гөлнар, Гөлшат һәм Гөлназ Набиуллиналарга рәхмәт сүзләрен җиткерәсебез килә.

Мәдәният - халыкның рухи куәтен, сәләтен, зәвыгын күрсәтүче көзге. Ул матурлыкка хезмәт итә, җанны, күңелне савыктыра. Ә матурлык кем өчен дә илһам, күңел күтәренкелеге, дәрт-дәрман чыганагы булып тора.

Хезмәтебез күзгә күренми, үлчәүләрдә үлчәнми, тынгысыз, мәшәкатьле. Безнең хезмәт - ул кешеләрне эштән соң ял иттерү, аларны үзара якынайту, яшь буынны тәрбияләү һәм рухи яктан баету. Мәдәният өлкәсе - матди кыйммәтләр белән бәяләнми, ул күңел кушуы, талант, матурлык өлкәсе. Киләчәктә дә мәдәниятле милләт булып саклану өчен безгә яшь буынны халкыбызның культура мирасы белән даими таныштырып тору, аны тарихыбызга хөрмәт белән карарга өйрәтү зарур.

Гомер мизгелләрдән тора. Хәер, гомер үзе дә бер мизгел генә. Шушы мизгелне лаеклы яшисе иде. Синнән соң да сагынып сөйләрлек игелекле эшләрең, изгелекле гамәлләрең калсын иде. Шуңа күрә дә алга таба да күркәм эшләребез белән халкыбызны сөендереп яшәргә, милләттәшләребезнең рухи дөньясын баетуда файда китерә алырлык гамәлләр башкарырга насыйп булсын иде. Без кабызган утлар сүнмәс алар!




Без кабызган утлар


Без кабызган


кабызган утлар


Без кабызган утлар


Без кабызган утлар





